**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.04.2015 № 349

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы корреспондент пунктын (корпунктын) Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихының төбәк музее каршында 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы Интернет-музеен булдыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 2822-р номерлы боерыгын үтәү максатында, фашизмны Бөек Җиңү эшенә татарстанлыларның өлеше турында мәгълүмат базасын туплау һәм җыю, сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре, иҗтимагый ветераннар һәм эзләнү оешмалары белән хезмәттәшлек итү, ветераннарга ярдәм итү, үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы Интернет-музее корреспондент пунктын (корпункт) булдырырга.

2. Раслау:

-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы корреспондент пунктының (корпунктының) 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы Интернет-музеен оештыру комитеты.

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының корреспондент пункты (корпункты) 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы Интернет-музее турында нигезләмә.

3. Корпункт администраторы вазыйфаларын Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарих музееның баш саклаучысы Морзаханова Флюра Җамал кызына йөкләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә социаль-мәдәни үсеш буенча йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин